Тәрбиячеләр һәм мәктәпкәчә хезмәткәрләр конен 27 сентябрьдә билгеләп vтv кабул ителде. Мәктәпкәчә белем бирv һонәрендә эшләvчеләр, ягни тәрбиячеләр, баланын шәхес буларак vсешендә зур роль уйныйлар. Чонки ата-аналардан тыш, балалар кvп вакытларын нәкъ менә алар белән бергә vткәрә.   Балалар белән эшләv очен билгеле бер кvнекмәләргә, талантка ия булырга кирәк. Һәр кон тәрбияче, торле кыенлыкларга очрашып, һәр баланын уй-фикерләренә һәм хисләренә карата vзенчәлекле ачкычынны табу очен кvп коч куя.

Кадошкино бистәсендә бер балалар бакчасы - «Теремок» эшләп килә. Катнаш тордәге корылма vз эченә ике корпусны ала, чонки ана 2017 елда «Кояшлы» бакчасы кушылды. Хәзер биредә 186 бала тәрбияләнә, 10 торкем эшли. «Теремок»нын жтәкчесе Людмила Викторовна Лимасова. 1994 елдан анын хезмәт юлы башлана, башта мәктәптә укытучы була, ә 2011 елдан ул балалар бакчасы модире буларак башта «Кояшлы»да, ә 2013 елдан «Теремок»та эшли башлый. Эшкә тотынгач, биналарны, ишегалды территориясен, азык-толек блогын, кер юу бvлмәләрен, торкемнәрне, йокы һәм киенv-чишенv урыннарын тозекләндерv буенча чиксез мәшәкатьләр башлана. Людмила Викторовна vзенен икенче йорты очен жан атып яши. Ул бик ачык кеше; анын кабинетына хезмәткәрләр барлык сораулар белән бара, чонки мона унай атмосфера бар. Ә балалар бакчасында бик унайлы, чиста һәм матур. Бу барысы да хезмәткәрләр тырышлыгы белән булдырылган. Чонки биредә байтак еллар, башкалар белән бергә, шундый тәрбиячеләр - Римма Халил кызы Маркина, Римма Әбубәкәр кызы Никулина, Аэлита Халил кызы Якубова тырышып эшлиләр. Тәрбияченен эше ярдәмчеләрдән башка момкин тvгел. Алар белән бергә Надия Хәсән кызы Мангутова киләчәк буынга тиешле тәрбия бирvгә, сәламәтлекләрен саклауга зур олеш кертә.

Һонәри бәйрәмдә барлык мәк- тәпкәчә белем бирv учрежде ниеләре хезмәткәрләренә сәла- мәтлек, иминлек, тормышыгызда якты һәм шатлыклы мизгелләр кvп булсын, гаилә рухын һәм бәхетле балачак атмосферасын саклап калуларын телибез.

Н.ХӘЛИЛ